
# *Иркәң буласым килә*

*Лена Шагыйрьҗан сүзләре*




mp
Ир - кәң бу - ла - сым ки - лә, би - кәң бу - ла - сым
ки - 5 лә. Жил - лә - ре - нә буй - сы -
ныр - лык жил - кән бу - ла - сым ки - лә.
Иә ко - лың бу - лыр и - дем,




1985

Иркәң буласым килә,
Бикәң буласым килә.
Җилләреңә буйсынырлык
Җилкән буласым килә.

К у ш ы м т а:

Йә колың булыр идем,
Уң кулың булыр идем.
Сагышлы, моңлы сазыңның
Бер кылы булыр идем...

Иркәм, дип дәшүләрең,
Бикәм, дип дәшүләрең...
Тутырып-тутырып карамадың,
Әллә читләшүләрең...

К у ш ы м т а:

Йә көнең булыр идем,
Ак төнең булыр идем.
Туфрагыңда чәчәк аткан
Бер гөлең булыр идем...